**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әгерҗе авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әгерҗе авылы — № 8-2 — «22» сентябрь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының 2015 елның 21.05 131-8 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставы белән

Әгерҗе авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге Советының 2015 елның 21.05 131-8 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү невәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3 нче бүлектә:

а) 3.6 нчы пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында бюджет законнары нигезендә Азнакай муниципаль районы һәм «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертелә, анда тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар карала.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Азнакай муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмаган очракта, алар Азнакай муниципаль районы бюджетына ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.»;

б) 3.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче, өченче абзацлар өстәргә:

«Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булганда, түләүсез түләүсез файдалану шартнамәсе нигезендә муниципаль мөлкәт тапшырыла.

Түләүсез файдалану шартнамәсе сроклы була һәм килешү гамәлдә булу чорына төзелә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 3.9 пункт өстәргә:

«3.9. Күрсәтелгән килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Әгерҗе авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.»;

**1.2. 4 нче бүлектә:**

а) 4.6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында бюджет законнары нигезендә Азнакай муниципаль районы һәм «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертелә, анда тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар карала.

Финанс средстволарын максатчан файдаланмаган очракта, алар Әгерҗе авыл җирлеге бюджетына ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.»;

б) 4.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче, өченче абзацлар өстәргә:

«Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булганда, түләүсез түләүсез файдалану шартнамәсе нигезендә муниципаль мөлкәт тапшырыла.

Түләүсез файдалану шартнамәсе сроклы һәм килешү гамәлдә булу чорына төзелә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 4.8 пунктны өстәргә:

«4.8. Күрсәтелгән килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.»;

1.3. 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.3 пункт өстәргә:

«5.3. Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә.

Бәхәсне сөйләшүләр уздыру яисә килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.»;

1.4. 6 нчы бүлектә:

а) 6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче - дүртенче абзацлар өстәргә:

««Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- Яклар килешүе буенча;

- в бер яклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 6.4 пункт өстәргә:

«6.4. Килешү гамәлдә булу вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы файдаланылмаган финанс чараларын, матди ресурсларны һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган мөлкәтне кире кайтара.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис                                        Н.Н.Хәсәнов